ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

11.01.2018 — с. Печищи — № 2

«Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында»

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына хезмәт өчен түләүнең минималь күләмен хезмәткә сәләтле халыкның яшәү минимумына кадәр арттыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 28 декабрендәге 421-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегенең бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә эш вакыты нормасын үтәгән хезмәткәрләргә хезмәт хакын минималь хезмәт хакыннан ким булмаган күләмдә - 9 489, 00 сум түләүне тәэмин итергә
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Печищи авыл җирлеге башлыгы урынбасары — Т. С. Нуруллин